# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

2024 елда Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Песәй авыл җирлеге Песәй торак пунктында гражданнарның үзара салымын кертү турында

06.04.2024 ел № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы «Песәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгының 2024 елның 26 мартындагы 1 номерлы 2023 елның 22 ноябрендәге 1 номерлы «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Песәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге составына керүче Песәй авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында", 2023 елның 22 ноябрендәге 2 номерлы " 2024 елда Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Песәй авыл җирлегенең Песәй авылында гражданнарның үзара салымнарын кертү турында" гражданнар җыеннары карарларына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында карары нигезендә
**КАРАР ЧЫГАРДЫ:**

1. 2023 елның 22 ноябрендәге 1 номерлы «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Песәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге составына керүче Песәй авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында", 2023 елның 22 ноябрендәге 2 номерлы " 2024 елда Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Песәй авыл җирлегенең Песәй авылында гражданнарның үзара салымнарын кертү турында" гражданнар җыеннары карарларына үзгәрешләр кертергә һәм чараларны түбәндәгечә бәян итәргә:

«1) Песәй авылында Мичурин, Чишмә, Тукай, Степная урамнары, Степная тыкрыгы буенча торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, (авыл эчендәге юлларны ремонтлау (вак таш сатып алу, ташу, килешү буенча эшләр өчен түләү), кардан юлларны чистарту Песәй авылында) ;

2) су белән тәэмин итү һәм су чыгару системаларын, су күтәрү манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (Песәй авылында 2 (ике) данә скважина өчен тирәнлек насосы сатып алу);

3) каты коммуналь калдыклар туплау мәйданчыкларын төзү, каты коммуналь калдыклар җыю өчен контейнерлар сатып алу, санкцияләнмәгән чүплекләрне бетерү (санкцияләнмәгән чүплекләрне бетерү буенча хезмәтләр Песәй авылында).

4) торак пункт территориясен төзекләндерү (Сабантуй бәйрәмен үткәрү мәйданчыгында сәхнә кую, Мәктәп тыкрыгында агачларны кисү, койма кую, үлән чабу Песәй авылында)

5) янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (Яшьләр урамында, Тукай урамында янгыннарны мониторинглау өчен видеокүзәтү камералары урнаштыру Песәй авылында)

2. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә, 10 көн эчендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында. www mendsleevsk.tatarstan.ru "Песәй авыл җирлеге" бүлегендә бастырып чыгарырга

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Менделеевск муниципаль районы
Песәй авыл җирлеге башлыгы ____________ В.И.Мөхәмәтгалеев

(имза) (имза аңлатмасы)